ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 статьясындагы 1 өлешенең 8 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) даими яшәү урыны булмаган затлар, аларга, Россия Федерациясенең аз санлы җирле халыкларына караган затлардан булган баланы уллыкка (кызлыкка) алган очракта, Россия Федерациясенең күчмә һәм (яисә) ярым күчмә тормыш рәвеше алып баручы һәм даими яисә өстенлекле яшәү урыны булмаган аз санлы җирле халыкларына карый торган затлар керми;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 16 март
№ 13-ТРЗ